ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22. 12. 2021 Олы Кайбыч ав. № 509

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү турында

Социаль, икътисадый, экологик һәм башка факторлар җыелмасыннан чыгып, территорияләрнең билгеләнешен ачыклау, авыл җирлекләре территорияләрен тотрыклы үстерүне тәэмин итү, уңай тормыш шартлары булган территорияләрне комплексы тотрыклы үстерүне, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү максатларында; «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14,15 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләүгә керешергә.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка таратырга) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында (https://kaibici.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Әхмәтов Ф.Ш.ка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы
Башкарма комитет
Җитәкченең беренче урынбасары Э. Х. Заһидуллина